№ 30 (1157), 23 июль 2012 ел

кояшның баешыннан алып иртәгесе көннең өйләсенә кадәр дәвам итә.

Рамазан уразасының һәр көне өчен аерым нијат ителә, чөнки арага төннәр керә. Аннан соң, көннең уразасы — мөстәкыйль бер гыйбадәттер. Шуның өчен бер көн ураза бозылса да, башка көннәргә тәэсире юк.

### Уразалы кеше өчен мөстәхәб эшләр

Ураза тотучы кешенең сәхәр ашына торуы мөстәхәбтер. Сәхәр ашын төн бетәр алдыннан ашыйлар. Ягъни сәхәрне никадәр кичектерсәң, шулкадәр әйбәт. Әлбәттә, таңның беленүенә кадәр бик аз вакыт калмасын.

Ифтар ашын мөмкин кадәр тизрәк, ягъни ахшам намазыннан элек ашау мөстәхәбтер. Шул очракта, ачлык тойгысы намазга комачау итмәс. Ураза тоткан кешенең якыннарына һәм фәкыйрьләргә гадәттәгесенә караганда күбрәк ярдәм итүе мөстәхәбтер.

Уразалы кеше мөмкин кадәр күндез һәм кичен Коръән укыса, зикер итсә, Пәйгамбәребезгә (с.г.в.с.) салават китерсә, гыйлем белән шөгыль итсә, бу гамәлләре мөстәхәб булыр.

Уразалы кешенең буш һәм мәгънәсез сүзләр сөйләүдән, гайбәт таратудан, сүз йөртүдән тыелуы да мөстәхәбтер. Гайбәт таратудан, сүз йөртүдән качу исә һәрвакыт вәҗибтер. Тик моның әһәмияте Рамазан аенда аеруча зур була.

### Ураза тотканда мәкруһ һәм мәкруһ булмаган эшләр

Уразалы кешенең суга чылатылган теш чистарткычы куллануы, имам Әбү Йосыф фикеренчә, мәкруһтыр. Әмма башка галимнәрнең сүзенә караганда, иртән яки кояш батканнан соң коры һәм юеш теш чистарткычы куллануда кәраһәт юк.

Уразалы кешенең истинҗа вакытында (олы тәһарәт алганда) артык күп итеп су куллануы мәкруһтыр. Тәһарәттә авызына яки борынына кирәгеннән артык су алуы мәкруһтыр. Ураза иясенең үзен акларлык бер сәбәбе дә булмыйча, пешкән ризыкны авыз итеп каравы мәкруһтыр. Әгәр инде берәр хатын-кызның ире бик холыксыз икән, ул вакытта әлеге хатын пешергән әйбернең тозлы-тозсыз яки баллы-балсыз булып пешкәнен белер өчен, аны йотмау шарты белән авызга алырга мөмкин.

Үз-үзенең ныклыгына ышанмаган ураза иясенең хатынын үбүе һәм назлавы мәкруһтыр. Уразалы кеше хуш исле чәчәкләрне иснәсә, сөрмә тартса, мыек кремы (мае) кулланса, мәкруһ түгел.

Шәригать сәяхәтчеләргә, йөкле хатыннарга, бала имезүче хатыннарга, авыруларга ураза тотмаска рөхсәт итә. Ләкин алар да башка вакытта көнгә көн ураза тотуны бурыч итеп куя. Кайбер галимнәр әйтүенчә, картлар-карчыклар, физик яктан хәлсезләнгән кешеләр, авыр физик хезмәттә эшләүчеләр ураза тотмаган көннәре өчен, Аллаһыдан кичерү сорап, бер ярлыны ашата ала.

### Көн дә уку тиеш

Кояш чыгарга 2 сәгать кала, ягъни иртәнге намазның азанына 20 минут чамасы иртәрәк сәхәр ашап бетереп, фарыз уразаны тоту өчен нијат әйтелә: *«Нәүәйтү ән әсүумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләәһи тәгаалә»*.

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен ихласлык белән таң вакытыннан башлап Кояш батканга тикле Рамазан уразасын тотарга нијат кылдым».

Кояш баеп, ахшам намазына азан әйтелгәч, 5 минут чамасы көтеп, чираттагы көннең уразасы тәмамлангач, бер чеметем тоз яки бер йотым су, шулай ук хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу сөннәттер (саваплы).

Авыз ачканнан соң укый торган дога: *«Әллаахуммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галләә ризкыйкә әфтарту фәгъфирли йәә гаффаару мә каддәмтү вә мәә әххәртү»*.

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым һәм Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризалыгың белән авыз ачам. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, әүвәлге гөнаһларымны да, киләсе гөнаһларымны да ярлыка».

**Камышлы һәм Кләүле районнары имам-мөхтәсибе Габдулла хәзрәт МӨХӘММӘТКӘРИМ әзерләде.**

## Тәравих намазы хакында

Тәравих намазы Рамазан аенда кылына һәм сөннәт мөвәкдә санала. Аны ирләр дә, хатыннар да укырлар. Бигрәк тә өйдә яки мәчеттә ирләр, җәмәгать белән, тәравих намазларын укыйлар икән, яхшыдыр һәм савабы да артыктыр.

Тәравих намазы егерме рәкәгать итеп башкарыла. Һәр дүрт рәкәгатьтән соң бер сәлам бирергә яки егерме рәкәгатьнең барысын укыганнан соң, сәлам әйтеп тәмамларга мөмкин. Әмма һәр ике рәкәгатьтә бер сәлам биреп, һәр дүрт рәкәгать арасында дүрт рәкәгать намаз уку вакыты кадәрле утырып тору сөннәт-мөстәхәб санала. Шушы утыру вакытында, әгәр дә теләгендә бар икән, Коръән укырга мөмкин, яки тәсбих әйтергә, яисә тик торырга да ярый. Бу утыруны «ял итү», ягъни «тәравихәт» дип йөртәләр.





Тәравих намазына бу рәвешле нијат ителер: «Нијат иттем бу кичәнең тәравих намазын укырга!» - дип. Әгәр дә намазга оесаң: «Оедым шушы имамга!» - дип тә өстәү шарт. Сәлам биргәннән соң дөнья сүзләре сөйләшенмәсә, ашамасаң-эчмәсәң, дөнья гамәлләрен башкармасаң, шул бер нијат белән егерме рәкәгатьне ахырына кадәр башкару дөрес булыр. Тәравих өчен егерме рәкәгать бер намаз исәпләнә.

Тәравих намазы ястү намазының вакыты кергәннән алып, тәмамланганчы, ягъни соңгы минутына кадәр, теләсәләр, кич ахырында, яки төн уртасында, яки таңга кадәр укылыр. Ләкин ястү намазының фаразыннан соң кылыныр. Аннан алда дөрес булмас. Ә витр намазы тәравихтан соң укылыр, әмма алдан укылса да ярый.

Бер кеше имамга тәравих намазы башлангач җитешсә, ул башта ястү намазының фаразын һәм сөннәтен укыр, соңыннан имамга тәравих намазына оер. Имам белән витр намазын кылып, соңыннан, ничә рәкәгать тәравих намазы калган икән, аларны каза итеп укыр. Теләсә, тәравих намазын башта каза итәр, витр намазын соңыннан башкарыр. Икесе дә дөрес. Әгәр дә имам һәм җәмәгать тәравих намазын укыганда, егерме рәкәгать укыдык инде, юк, унсигез генә булгандыр, дип шикләнә калсалар, санны ачыклый алырлык төгәл фикергә килмәсәләр, ул вакытта һәрберсе аерым-аерым итеп тагын ике рәкәгать намаз укыр. Чөнки бу ике рәкәгать артык булса, нәфел намазыннан китәр. Ә нәфел намазларын җәмәгать белән уку мәкруһ санала, шунлыктан аны аерым-аерым укырга тиешледер.

Тәравих намазларында иң азы «Фәтиха» сүрәсеннән соң өч кыска аять яки шушы өч кыска аять озынлыгында бер озын аять уку вәҗиб. Ике рәкәгатькә бер яки дүрт сәлам биреп, һәр утырганда салават әйтеп, аякка баскач, «Сүбехәнәкә...», «Әгүзү...», «Бисмиллаһ...» белән башлап укырга кирәк. Рөкүгъ хәленнән торганда, ике сәҗдә арасында тәгъдил әркәнне онытып калдырмау шарт. Чөнки тәгъдил әркән фарыз һәм вәҗиб булып тора. Әгәр дә фарыз икән, ул вакытта аны онытып калдырудан намаз бозылыр. Әгәр дә онытып калдырылса, сәҗдәи сәһү тиешле булыр.

## Фарыз булмаган ураза хакында

*«Кем дә кем Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен бер генә көнне булса да уразада кичерсә, Аллаһы Тәгалә бу бәндәнең йөзен уттан 70 ел саклар»*, – дигән Рәсүлуллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләм (хәдис-шәрифне хәзрәте Әбү Сәгыйд радыйаллаһү гәнһе тапшырган).

Нәфел яки сөннәт ураза көннәре:

- мөхәррәм аеның 9 һәм 10нчы көннәрендә;
- һәр дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә;
- һәр айның 13,14,15нче көннәрендә;
- Дауд галәйһис-сәлләм шикелле көнаралаш;
- Рәҗәб аеның теләгән көнендә;
- Шәгъбән аеның теләгән көнендә, аеруча 15нче көнендә;
- Шәүвәл аеның алты көнендә;
- Зөлхиҗҗә аеның беренче 9 көнендә;
- Гарәфә көнендә.

**(“Татар мөселман календаре”ннан)**

## Фитыр садакасы хакында

*«Аллаһының Рәсүле (с.г.в.) һәрбер кешегә – кол булса да, азат булса да, ир җенесе булса да, хатын-кыз җенесе булса да, яшь сабый булса да, олы кеше булса да, тәмердән (финик) бер саг (2,4 кг) яки арпадан бер саг итеп фитыр садакасы бирергә фарыз кылды», – диде Габдулла ибн Гомәр (Аллаһы алардан разый булсын (Бохари, 1407). Икенче хәдистә Әбү Сәгыйть әл-Худри хәзрәтләре әйтә: «Фитыр садакасын ризык белән бер саг, яки арпа белән, яки тәмер белән, яки кипкән корт белән, яки йөзем белән бирә торган идек» (Бохари, 1410). Бу хәдисләрдән аңлашылганча:*

*1. Фитыр садакасы өйдәге кеше санынннан чыгарыла. Бу санга балалар да, олылар да керә. Әгәр өйдә ир белән хатын булып, аларның өч сабыйлары бар икән, ир кеше биш кеше исәбеннән, сабыйлары ураза тотмаса да, фитыр садакасы бирә. Ягъни 5 саг ризык, арпа, бодай, дөге һ.б.*

*2. Фитыр садакасы асылда ризык белән бирелә. Кайда нинди ризык кулланыш тапкан һәм нәрсә белән кулыннан килә, шулай бирә.*

### Фитыр садакасын акча белән бирергә ярыймы?

Күп галимнәр садаканы ризык белән бирергә, диләр. Ләкин кайберләре, шулай ук безнең мәзһәб галимнәре, акча белән бирсәң дә ярый, диләр. Тик акчаны нинди микъдарда бирергә? Моны һәр кеше үзе хәл итә. Әгәр ул арпа хисабыннан чыгара икән, арпаның микъдары Мәдинә сагы белән - 2,4 кг. Багдад сагы белән – 3,6 кг. Уртача 3 кг арпа хакы хисабыннан бирә. Шулай ук башка ризыкларның да хакын 3 кг исәбеннән бирсәң ярый. Акча нијате белән бирмисез, ә нинди дә булса ризык хисабыннан нијат итеп бирәсез. Бүген арпаның 1 килограммы 7-10 сум булса, йөзем, тәмер – 60-80 сум, башкорт корты – 100 сум.

Арпа хисабыннан фитыр садакасы бирсәң, быел 21 - 30 сум, кипкән йөзем, тәмер хисабыннан 180 - 240 сум, кипкән корт исәбеннән - 300 сум. Һич шикләнергә ярамый, бөтенесе дә дөрес. Динебез шулай киң, аптырарга түгел. Аллаһыга шөкер.